Березняк авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2023 елның 18 декабре № 32

Березняк авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Березняк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Березняк авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 31 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 9 номерлы, 2020 елның 23 мартындагы 8 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 4 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 16 номерлы, 2023 елның 3 февралендәге 3 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 22 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Березняк авыл җирлеге башлыгына классы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Р.Ф.Шәрипов